| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 22 июль № 532

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлеген һәм Татарстан Республикасының дәүләт программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 31 декабрь, 1199 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлегенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлеген һәм Татарстан Республикасының дәүләт про-граммаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 31 декабрь, 1199 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 26 апрель, 282 нче; 2013 ел, 29 апрель, 294 нче; 2013 ел, 29 июнь, 454 нче; 2013 ел, 19 июль, 507 нче; 2013 ел, 24 октябрь, 789 нчы; 2013 ел, 31 декабрь, 1110 нчы; 2014 ел, 15 март, 157 нче; 2014 ел, 14 апрель, 242 нче; 2014 ел, 11 июнь, 405 нче; 2014 ел, 9 июль, 475 нче; 2014 ел, 5 сентябрь, 644 нче; 2015 ел, 6 май, 326 нчы; 2015 ел, 16 май, 346 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлегенә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

түбәндәге эчтәлекле 30 нчы пункт өстәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «30 | 2015 – 2020 елларга Татарстан Республикасында талантлар белән | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты | «Казан сәләтлеләр ачык университеты 2.0» автоном коммерциячел булмаган оешмасы (килешү | талантлы, сәләтле балаларны, яшьләрне, остазларны билгеләү һәм аларга ярдәм күрсәтү; |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | стратегик идарә итү | | буенча), Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Татарстан Республикасы Фәнәр академиясе (килешү буенча), «Яшьләр дипломатиясе академиясе» яшьләр иҗтимагый оешмасы (килешү буенча); Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы | балаларның, яшьләрнең интеллектуаль-иҗади потенциалын үстерү; фәнни иҗат мәйданчыклары челтәрен үстерү; балаларның, яшьләрнең инициативаларына һәм проектларына булышлык күрсәтү; формаль булмаган белем бирү программаларын тормышка ашыру; экспертлар, эш бирүчеләр белән системалы рәвештә хезмәттәшлек итү аша укучы яшьләрне үстерү, һөнәри сынау һәм аларның стажировкалары буенча даими гамәлдә булган система булдыру; талантлар белән идарә итүдә ведомствоара хезмәттәшлекне үстерү». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\532.doc